ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.02.2025 Балык Бистәсе штп. № 29пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 07.07.2022 №143пи карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеме белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге" муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмат-методик бүлек хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы икенче өлеше, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 22.11.2024 ел, №под-1950/24 боерыгы белән «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Муниципаль район мәгариф идарәсе (бүлеге)» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмат-методика бүлекләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы үрнәк нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында", Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 29.03.2022 №под-583/22 боерыгы белән расланган муниципаль берәмлекләр мәгариф педагогик хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручыларга КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 07.07.2022 №143пи карары (23.09.2024 №267пи редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеме белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге" муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмат-методик бүлек хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1) II бүлектә 1 пунктны кушымтада бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә:

1. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ структурасындагы мәгълүмат-методика бүлеге хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификацион дәрәҗә | Вазифаның атамасы | Айга база окладу күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем бирү, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы үткән затка “бакалавр”, “магистр” яисә “дипломлы белгеч” бирү белән расланган югары һөнәри белем " |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификацион дәрәҗә | Методист | - | - | 20246,0 |
| Дүртенче квалификацион дәрәҗә | Өлкән методист | - | - | 20251,0 |
| | | | | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Беренче квалификацион дәрәҗә | Муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек структур бүлекчәсе мөдире (башлыгы) урынбасары;<br>Муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек структур бүлекчәсе мөдире (башлыгы) ; | - | - | 20329,0<br>20405,0 |

1.2) «Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы кызыксындыру характерындагы түләүләр каралган ведомство (тармак) бүләкләре» бүлегенең 1 пунктына кушымтага түбәндәге эчтәлекле 1.8 пункт өстәргә:

«1.8. «Яшьлек һәм Профессионализм» күкрәк билгесе.

2. Әлеге карар үз гамәлен 2025 елның 1 гыйнварынан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе начальнигы И.М. Садыйковка йөкләргә.

Җитәкче Д.А. Сатдинов